**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

**КАРАР**

27.02.2015 Яр Чаллы № 2487

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт
бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 201 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 02.11.2010 № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 05.07.2012 ел, №2104 Башкарма комитет җитәкчесе карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт формасын һәм формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы, Тукай районы прокуратурасының 16.07.2015 елгы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. «Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» Башкарма комитет җитәкчесенең 2014 елның 10 апрелендәге 1476 номерлы карарының 10 кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга.
3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары, төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев